Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм вакыты турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2.05.2006 елдагы 59-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары турында бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына үз эшләрендә әлеге Нигезләмәгә таянып эш итәргә кирәк.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башлыгы урынбасары Е. Г. Курковка йөкләргә.

Тәтешмуниципаль районы

башлыгы Р. Х. Сафиуллов